| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.09.2024 № 1050

Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 08.08.2012 елгы 808 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга һәм 2036 елга кадәр чорга Нурлат шәһәрен җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында» 28.01.2022 № 109 карары белән Нурлат шәһәре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә үзәкләштерелгән, өзлексез җылылык белән тәэмин итүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат шәһәре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешма статусын-Нурлат шәһәренең "Нурлат җылылык челтәрләре" акционерлык җәмгыятенә бирергә. (ИНН 1632009786, ОГРН 1061665039149), урнашкан адресы: 423040, Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Гагарин ур., 7 й.

2. Гарантияләүче оешманың эшчәнлек зонасы итеп Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы территориясен билгеләргә.

3. Нурлат шәһәренең "Нурлат җылылык челтәрләре" акционерлык җәмгыятен Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан җылылык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итү системаларын эксплуатацияләү буенча эшчәнлегендә «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законга таянырга киңәш итәргә.

4. Нурлат шәһәренең «Нурлат җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыятенә Нурлат шәһәренең «Нурлат җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган җылылык белән тәэмин итү

челтәрләренә билгеләнгән тәртиптә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары абонентларын җылылык белән тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре чикләрендә җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешманы билгеләү турында» 19.04.2018 ел, № 2 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарны Нурлат шәһәренең «Нурлат җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте адресына җибәрергә.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин